РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 29 марты** **Чистай шәһәре** **№ 45**

Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма
комитетының «2021 елга Чистай шәһәре торак
фондында торак бинадан файдаланган өчен (наем
өчен түләү), торак урыннарны карап тоткан һәм
ремонтлаган
өчен түләү күләме турында» 2020 елның
28 декабрендәге 265 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр һәм идарә итү, тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта һәм тиешле дәвамлылыктан артып киткән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту һәм ремонтлау эшләре башкарылган очракта торак урынны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма комитетының «2021 елга Чистай шәһәренең торак фондында торак бинадан файдаланган (наем өчен түләү), торак урыннарны карап тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләме турында» 2020 елның 28 декабрендәге 265 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаның 4 юлыннан түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга: «Торак бинага капиталь ремонт»; «аена торак урынның кв.м гомуми мәйданы»; «6,11»; «6,11»; «100%».

2. Чистай муниципаль районы шәһәр Башкарма комитетының ЖКХСТЭС һәм ДХ бүлегенә әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садиковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов